ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

03.11.2020 д. им. М. Вахитова 8

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең
Бакча-Сарай поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020нче елның 19нчы ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай поселогы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020нче елның 19нчы ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай поселогы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

   1 этап: Бакча-Сарай поселогы, Дальняя урамы, Приволжская урамы, Центральная урамында яшәүчеләр.

   2 этап: Бакча-Сарай поселогы, Нагорная урамы, Молодежная урамы, Лесная урамында яшәүчеләр.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

- Бакча-Сарай поселогы эчендәге һәм керү юлларын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннарын үткәрергә:

   1 этап: Бакча-Сарай поселогы, Приволжская урамы буенча 8нче номерлы йорт янында

2 этап: Бакча-Сарай поселогы, Нагорный урамы буенча 5нче номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф. Р. Кәримов